## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең
Кадрәк торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**29.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, армиядә хезмәт итүчеләр, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. *Кадрәк торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, буртлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);*
2. *Кадрәк торак пунктында су күтәрү манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);*
3. *Кадрәк торак пунктында юлларны грейдирлау (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
4. *Кадрәк торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү);*
5. *Кадрәк торак пунктында юл кырыен чаптыру(килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
6. *Кадрәк торак пункты зиратында куакларны кисү (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
7. *Сабантуй уздырыла торган урында ремонт эшләре үткәрү (профтүбәләрне буяу, түбә астындагы идәнне бетонлау, материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
8. *АЦ-40 (ЗИЛ-431412 янгын сүндерү машинасына хезмәт күрсәтү (за частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт хакы).*

3. Җыенның нәтиҗәләрен Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://menzelinsk.tatarstan.ru/),хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы ____________ Х. Х. Нәбиуллин
(имза)